ГЛАВА
ГОРОДИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Клубная, дом 6а,
село Городище, 422481
ИНН 1617003250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГОРОДИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Клуб урамы, 6а нче йорт,
Городище авылы, 422481

Тел.: (84375) 3-51-16, 3-51-30, факс: (84375) 3-51-16, e-mail: Gor.Drz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2021 ел №13

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аоардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Городище авыл җирлеге Советынын 14.10 2019 ел, №54/1 карары (15.11.2021 ел, №52/5 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уткеру тәртибе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Чүпрәле муниципаль районының Яңа Чәке Городище җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2021 елның 30 ноябренә 09:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләп куярга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Чәке авылы, Үзәк урам, 22а йорт, Яңа Чәке авыл клубы.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Чәке авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Яңа Чәке авылы Үзәк урамы буенча гамәлдәге юлга вак таш түшәү;

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Городище авыл
җирлеге башлыгы: Н.А. Усмендеев